КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 сентябрь г.Казань № 908

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларыннан субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 20 март, 210 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү

өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 20 март, 210 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 8 енә кадәр, Министрлыкка электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә бу Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) транспорт оешмаларына алынып бетмәгән керемнәрне компенсацияләү күләмен исәпләү методикасы нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) транспорт оешмаларына алынып бетмәгән керемнәрне компенсацияләүгә субвенцияләр күләме турында исәп-хисап белешмә кәгазьләрен (алга таба – исәп-хисап белешмә кәгазьләре) һәм бу Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар (алга таба – хисаплар) кертә.

Министрлык бу пунктның беренче абзацында каралган документларны теркәгән көннән биш эш көне эчендә аларны карап тикшерә һәм субвенцияләрне күчерү турында яки субвенцияләрне күчерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Субвенцияләрне күчерүдән баш тарту өчен документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы) һәм (яки) бу пунктның беренче абзацында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы нигез булып тора.

Субвенцияләрне күчерүдән баш тарту турындагы хәбәрнамә, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлык тарафыннан субвенцияләрне күчерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә җирле үзидарә органына җибәрелә.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары субвенцияләрне күчерүдән баш тарту турында хәбәрнамә алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә документларны баш тарту сәбәпләрен бетерү шарты белән яңадан җибәрергә хокуклы.»;

4 пунктта «бирелергә тиешле субвенцияләрнең күләме турында ирекле формада заявка» сүзләрен «бу Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субвенцияләр бирүгә заявка» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субвенцияләр Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлекләрнең финанс органнары өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган муниципаль берәмлекләр бюджетларының бердәм счетларына күчерелә.»;

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Агымдагы финанс елның декабренә бирелгән субвенцияләр күләме әлеге чор өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бирелергә тиешле субвенцияләрнең күләменнән кимрәк булган очракта, җитеп бетмәгән сумма Министрлык тарафыннан агымдагы елдан соң килә торган елның 31 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына күчерелә.»;

әлеге Тәртипкә 1, 2 һәм 3 нче кушымталар (карарга теркәләләр) өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 23 июль, б-1416 нчы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин